КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 ноябрь г.Казань № 950

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 589 нчы, 2020 ел, 26 ноябрь, 1066 нчы, 2021 ел, 13 март, 130 нчы, 2022 ел, 14 апрель, 353 нче, 2023 ел, 2 март, 199 нчы, 2023 ел, 14 июль, 835 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктта:

беренче абзацта «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» сүзләрен «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү тәртибе турында» 2025 елның 7 мартындагы 293 номерлы (алга таба - Каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләре)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Каты коммуналь калдыкларын туплау кулланучылар тарафыннан Каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләренең 30 пунктында күрсәтелгән ысуллар һәм урыннарда (мәйданчыкларда) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү турында килешү нигезендә башкарыла.»

түбәндәге эчтәлекле 2.20 пункт өстәргә:

«2.20. Әлеге Тәртипнең 2.16 – 2.18 пунктларын куллану, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү тәртибе турында» 2025 елның 7 мартындагы 293 номерлы карарының 3 пунктында күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып рөхсәт ителә.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Эре габаритлы калдыкларны туплау кулланучылар тарафыннан Каты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләрендә күрсәтелгән ысуллар һәм урыннарда (мәйданчыкларда) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү турында килешү нигезендә башкарыла.»

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Кулланучылар зур габаритлы калдыкларны контейнер мәйданчыкларына яки зур габаритлы калдыкларны саклау өчен махсус мәйданчыкларга үзләре китерәләр, әгәр мондый калдыкларны чыгару каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләргә шартнамәдә каралган башка шартларда гамәлгә ашырылмаса.»

8.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.7. Контейнерларда һәм (яки) бункерларда яки башка җыю җайланмаларында янучы, кызган яки кайнар калдыклар, кар һәм боз, терекөмешле яктырту җайланмалары һәм электр лампалары, батарейкалар һәм аккумуляторлар, медицина калдыклары, төзелеш һәм ремонт калдыклары (агымдагыдан тыш), шулай ук контейнерларга, чүп ташу машиналарына яки башка транспорт чараларына зыян китерергә мөмкин булган яки эшкәртү объектларының эшләү, энергетик юкка чыгару, каты коммуналь калдыкларны органик өлешләреннән ясалма туфраклар җитештерү, зарарсызландыру һәм каты коммуналь калдыкларны күмү режимын бозарга мөмкин булган башка калдыкларны урнаштыру тыела.»

8.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.8. Каты коммуналь калдыкларын контейнерлардан һәм (яки) бункерлардан яки башка җыю җайланмаларыннан тыш, шулай ук мондый калдыклар өчен билгеләнмәгән контейнерларга һәм (яки) бункерларга яки башка җыю җайланмаларына, шулай ук каты коммуналь калдыклар җыю урыны (платформа) янындагы территориягә урнаштыру тыела, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш.»

8.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.11. Агач-куаклык утыртмаларын карау вакытында барлыкка килгән калдыкларны каты коммуналь калдыклар туплау урыннарында (мәйданчыкларда) өю тыела.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин